# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

"Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында" 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 маендагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 11; 2005, № 5; 2009, № 6) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның бишенче абзацында "иҗтимагый әһәмияткә ия инициативаларны" сүзләреннән соң ", шул исәптән ихтыярый эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча инициативаларны" сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"ихтыярый эшчәнлекнең оешкан рәвешләренә ярдәм итү һәм аларны үстерү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру.";

3) 10 статьяның икенче абзацында "яшь гражданнарның" сүзләреннән соң "һәм ихтыярый эшчәнлекнең" сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 15 июне
№ 39-ТРЗ